**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: : 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАРЫ**

*2014 елның 3 марты* *88№*

2014 елга Әлки муниципаль районы гомуми белем бирү
оешмаларын финанслау нормативларын раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 1 өлешнең 11 пункты, Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2007 елның 11 декабрендәге «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 565 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2014 елга кушымталарны расларга:

Әлки муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга финанс чыгымнары нормативлары.

2. Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләр раслаган мәгариф оешмаларын финанслау нормативлары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

2013 елның 16 октябрендәге «2014 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Әлеге карарның 1 пункты.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2014 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.А. Платоновага йөкләргә.

ТР Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе А.Ф.Никошин

Расланган
Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районы Башкарма
комитетының 20____ елның ______
_____________ _____ номерлы карары

**Әлки муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга ФИНАНС ЧЫГЫМНАРЫ НОРМАТИВЛАРЫ**

| төр<br>гомуми белем бирү оешмасы төре | Территориаль урнашуы | Бер тәрбияләнүчегә финанс чыгымнары нормативы, елына |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 56357 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе (кадет интернат-мәктәбеннән тыш) | авыл җирлеге | 87039 |
| Кадет интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 112269 |
| Кадет мәктәбе | авыл җирлеге | 16506 |